ачык суд утырышында «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясының; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пунктының; шулай ук тулысынча аталган карарның аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Г.Җ. Галимҗанова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Р.Г. Сәхиева мәгълүматын, яклар — гражданка Г.Җ. Галимҗанова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге мөдире И.И. Фәттахов, Татарстан Республикасы Төзелеш,

архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының юридик бүлеге башлыгы Э.Ю. Латыйпова, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы юридик бүлегенең әйдәүче киңәшчесе Ф.М. Мөхәммәдиева, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна учреждениесе консультанты Г.Р. Нигъмәтуллина аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Р.С. Ибраһимов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинова чыгышларын тыңлап, суд утырышында тәрҗемәче — Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты Р.М. Болгарова катнашында, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Ж. Галимҗанова «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 3.7 пункты; шулай ук тулысынча аталган карар белән аны рәсми рәвештә бастырып

чыгару тәртибе буенча үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары тарафыннан кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларның текстлары рәсми рәвештә тиешле вакытлы басмаларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә басылып чыга һәм бер үк юридик көчкә ия була.

Тәртипнең 3.7 пункты техник заказчы яки махсус счет иясе капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүдә катнашучы комиссия әгъзалары таләбе буенча аларга күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү башланганчы капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышуны тәэмин итә дип күздә тота.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — күпфатирлы йорт советы рәисе урынбасары, әлеге йортта күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары буенча 2016 елның гыйнварыннан августына кадәр капиталь ремонт ясалган.

Гражданка Г.Җ. Галимҗанова Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы 2 өлеше эчтәлегеннән чыгып, капиталь ремонт үткәргәннән соң башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү актын имзалау кирәк булганын күрсәтә. Шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау бу күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре карары нигезендә үткәрелгән очракта, күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү акты шул исәптән күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат белән килештерелергә тиеш. Ләкин, мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, капиталь ремонт тәмамлангач, капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү акты әлеге күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан имзаланмаган булган. Мондый хәл, аның фикеренчә, урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен регламентлаштыра торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән хокукый җайга салу капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышу хокукын гамәлгә ашыру механизмын үз эченә алмаганлыктан, шулай ук, әлеге комиссиядә хәлиткеч тавыш бирү хокукы булмаганга күрә, милекчеләр фикерен игътибарга алмаска мөмкинлек биргәнлектән килеп чыга.

Моннан тыш, гражданка Г.Җ. Галимҗанова Тәртипнең дәгъвалана торган 3.7 пунктын аңлатуда һәм хокукый куллануда билгесезлек булуга күрсәтә, чөнки аның эчтәлегеннән акт имзаланганчы күпме вакыт алдан комиссия әгъзалары капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышырга тиешлеге һәм күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү башланганчы капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышу ни рәвешле тәэмин ителгәне күренми.

Шулай итеп, аның фикеренчә, Тәртипнең дәгъвалана торган 3.7 пункты аның капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортта торак урын милекчесе буларак конституциячел хокукларын боза һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми.

Гражданка Г.Җ. Галимҗанова шулай ук «Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары рәсми рәвештә татар телендә басылып чыкмаган дип саный.

Ул билгеләгәнчә, Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 статьясы буенча Татарстан Республикасында дәүләт телләре — Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә бертигез нигезләрдә кулланыла торган тигез хокуклы татар һәм рус телләре. Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы дәгъвалана торган карары «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда да (PRAVO.TATARSTAN.RU) (алга таба шулай ук — рәсми портал), 2016 елның 24 июнендәге 46 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгында да Татарстан Республикасының ике дәүләт телләренең берсендә генә — рус телендә басылып чыккан дип билгели.

Шуңа бәйле рәвештә гражданка Г.Җ. Галимҗанова дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы шулай ук аның конституциячел хокукларын боза дип саный, чөнки анда күрсәтелгән норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсми рәвештә бастырып чыгаруның мәҗбүри булуы яки, конституциячел таләпкә каршы, норматив хокукый актларны бары тик бер генә дәүләт телендә бастырып чыгаруның мөмкин булуы мәсьәләсендә билгесезлек бар.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.Җ. Галимҗанова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге

44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясын; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пунктын һәм тулысынча аталган карарны аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 8, 19 (беренче өлеш), 24 (өченче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 51 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасында дәүләт телләре — тигез хокуклы татар һәм рус телләре; Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә Татарстан Республикасының дәүләт телләре бертигез нигезләрдә кулланыла; законлы рәвештә булдырган мөлкәтне биләгәндә, аннан файдаланганда, аның белән эш иткәндә милекченең хокукларын чикләү, федераль законда каралган очраклардан гайре, рөхсәт ителми; Татарстан Республикасы законнары рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш; басылып чыкмаган законнар кулланылмый; кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген нинди милләттән булуына, теленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; Татарстан Республикасы куллanучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше һәм 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда фактлардагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала, бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә.

Шулай итеп, түбәндәгеләр әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004

елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясы;

— Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пункты; шулай ук тулысынча аталган карар аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча.

2. Россия Федерациясе Конституциясе кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауны, шулай ук мәгариф, мәдәният һәм аларның состав элементы буларак телнең гомуми мәсьәләләрен Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында булуын билгели (72 статья, 1 өлешнең «б», «е» пунктлары). Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы нигезендә Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча, шулай ук Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул ителгән федераль законнарга каршы килә алмый (2 һәм 5 өлешләр).

2.1. Россия Федерациясе Конституциясе Россия Федерациясе составындагы республикаларның конституциячел-хокукый статусы, шул исәптән дәүләт буларак та, үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларның республикаларның дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә Россия Федерациясенең дәүләт теле белән беррәттән кулланыла торган үз дәүләт телләрен билгеләү хокукын таный (68 статья, 2 өлеш).

Россия Федерациясе Конституциясенең 68 статьясын конкретлаштырып, «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы Россия Федерациясе халыклары телләре турындагы Россия Федерациясе законнары Россия Федерациясе Конституциясенә, халыкара хокукның гомумтанылган принципларына һәм нормаларына һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә нигезләнгәнен һәм әлеге Законнан, федераль законнардан һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларыннан, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары законнарыннан һәм башка норматив хокукый актларыннан гыйбарәт булуын билгели (1 статьяның 1 пункты). Күрсәтелгән Закон нигезендә Россия Федерациясе субъектлары гражданнарның аралашу, тәрбия, уку-укыту һәм иҗат итү телен ирекле сайлау хокукларын яклау турында законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итәргә хокуклы (3 статьяның 3 пункты).

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын кабул иткәндә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясе Конституциясе билгеләгән Россия Федерациясе һәм аның субъектлары карамагындагы мәсьәләләрне бүлешүгә нигезләнгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы (2 пункт) белән үзара бәйләнештә 29 статьясы (өченче өлеш) нигезендә үзенә караган вәкаләтен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

2.2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы законнары рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш; басылып чыкмаган законнар кулланылмый; кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый. Тиңдәш нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 15 статьясында (3 өлеш) каралган.

Әлеге конституциячел нигезләмәләргә «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» Россия Федерациясе Законының 13 статьясы тәңгәл килә, аның нигезендә республикаларның законнары һәм башка норматив хокукый актлары Россия Федерациясе дәүләт телендә рәсми рәвештә басылып чыгу белән беррәттән республикаларның дәүләт телләрендә рәсми рәвештә басылып чыга алалар (1 пункт). Шул ук вакытта федераль закон чыгаручы норматив хокукый актларны Россия Федерациясе субъектының дәүләт телендә бастырып чыгару өлешендә императив норма билгеләми, ә бу хокукны җайга салуны Россия Федерациясе субъектының үзенә калдыра.

Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар теленең кулланылышын тәэмин итү максаты белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы махсус Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, ул дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның хокукын гамәлгә ашыруга, татар тел культурасын яклауга һәм үстерүгә, татар халкы язуының тарихи традицияләрен дәвам иттерүне саклауга юнәлдерелгән.

Әлеге Татарстан Республикасы Законы нигезендә дәүләт теле буларак татар теленең статусы «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән өлкәләрдә аны куллану мәҗбүрилеген, яклауны һәм аңа ярдәм итүне, шулай ук дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның хокукын тәэмин итүне күздә тота (1 статьяның 1 өлеше).

Дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары тарафыннан кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларның текстлары рәсми рәвештә тиешле вакытлы басмаларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә басылып чыга һәм бер үк юридик көчкә ия була дип күздә тота. Әлеге Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең конституциячел тигезлеге принцибы кысаларында хокукый җайга салу гавами хакимият органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы дәүләт телләренең икесендә дә басылып чыгуын күз алдында тота. Бу тәртипне үтәү мәҗбүри, чөнки ул федераль һәм республика законнары таләпләренә нигезләнгән әһәмиятле процессуаль элемент булып тора. Моны Россия Федерациясе Конституция Суды да билгели, аның хокукый позициясе эчтәлегеннән күренгәнчә, норматив хокукый актларның легальлеге аларда билгеле, законга каршы килмәгән норматив эчтәлекнең (гомуми кагыйдәнең) булуын гына таләп итмичә, тиешле законлы форманы, кабул итү һәм халыкка җиткерү тәртибен үтәүне дә күздә тота; гамәлдәге хокукый җайга салу системасында андый норматив актны суд тарафыннан тикшерү үз эченә аның норматив күрсәтмәләренең эчтәлеге, акт формасы, шулай ук аны чыгарган субъект, кабул итү, бастыру һәм гамәлгә кертү тәртибе буенча федераль законга ярашлы булу-булмавын билгеләүне кертә (2015 елның 31 мартындагы 6-П номерлы Карар).

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы үзеннән-үзе гамәлдәге хокукый җайга салу системасында законнарның һәм башка норматив хокукый актларның бер генә дәүләт телендә басылып чыгу мөмкинлеген күздә тотмый һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 2, 8, 24 (өченче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы килми.

3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Тәртип торак законнары өлкәсенә карый, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлеш, «к» пункты) нигезендә Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы (2 һәм 5 өлешләр) буенча Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары бу өлкәдә федераль законнар нигезендә кабул ителә һәм аларга каршы килә алмый.

Күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт ясауны тәэмин итү буенча мөнәсәбәтләрне җайга салу Россия Федерациясе Торак кодексы һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм баш-

карма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан мөстәкыйль башкарыла торган уртак карамактагы предметлар буенча (федераль бюджеттан бирелгән субвенцияләрдән тыш) Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы хисабына әлеге органнар вәкаләтенә карый (тиешенчә 13 статьяның 8.3 пункты һәм 26.3 статьяның 2 пунктындагы 61 пунктчасы). Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны вакытында үткәрүне тәэмин итүгә юнәлгән һәм шул исәптән капиталь ремонт өчен кертемнәр хисабына формалашкан акчаларның максатка ярашлы тотылуын һәм ул акчаларның сакланышы тәэмин ителүне контрольдә тоту тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар кабул итәләр (167 статьяның 1 өлеше).

Федераль законнарның әлеге нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максаты белән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, аның 3 статьясы нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында кабул итү тәртибен билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә кертелгән (1 өлешнең 9 пункты).

Димәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен раслап, федераль һәм республика законнары белән үзенә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә нигезләнгән вәкаләтен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

3.1. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы Конституциясенә шул исәптән кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча туры килү-килмәвен билгели.

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе субъекты законнарын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибен билгеләү, Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, әгәр дә башкасы гомуми яки махсус федераль закон

белән расланмаган булса, Россия Федерациясе субъектының үз закон чыгару органының аерым хокукы (дискрециясе) булып тора (2005 елның 10 мартындагы 71-О номерлы Билгеләмә).

Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына. Әлеге Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы икенче өлеше нигезендә аның гамәлдә булуы кагылган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары системасына шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — республика Хөкүмәтенең норматив характердагы карарлары керә. Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын рәсми рәвештә бастырып чыгару көне итеп, карала торган Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы беренче өлешендә күрсәтелгәнчә, аларның тулы текстларын беренче тапкыр «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналында бастырып чыгару яисә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) яки «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) санала. Татарстан Республикасының күрсәтелгән норматив хокукый актлары башка язма басмаларда да бастырып чыгарыла, шулай ук телевидение һәм радио аша гомуми танышу өчен игълан ителә (халыкка җиткерелә), дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга җибәрелә, элемтә каналлары аша яки башка юл белән тапшырыла ала.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясындагы 6 пункты эчтәлегеннән аңлашылганча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе Татарстан Республикасы законнары белән генә түгел, башка норматив хокукый актлары белән дә билгеләнә. Әлеге норманы гамәлгә ашыру максаты белән «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карары кабул ителгән, аның нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре имзаланганнан соң 10 көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

Димәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карала торган карары гамәлдәге хокукый җайга салу система-

сында, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы нигезендә, аның әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә басылып чыгарга тиеш иде.

Эш материалларыннан күренгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карары рәсми порталда 2016 елның 22 июнендә рус телендә генә урнаштырылган, татар телендә исә — 2016 елның 21 ноябрендә генә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъва белдерелгән карарының текстын рәсми порталда төрле вакытларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштыру үзеннән-үзе аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танып өчен җитәрлек нигез дип санала алмый, чөнки бу гражданнарга аларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы карала торган норматив хокукый актның эчтәлеге белән танышу мөмкинлеген тормышка ашыруда объектив рәвештә киртәләр тудырмый. Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә дә тәңгәл килә, аның нигезендә, әгәр дә норматив хокукый акт рәсми рәвештә рус телендә басылып чыккан булса, бу вакытта республика телендә аның рәсми басмасы булмау факты гражданнар хокукларын боза дип карала алмый (2012 елның 22 ноябрендәге 2157-О номерлы Билгеләмә).

Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карары аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясына (өченче өлеш) туры килә дигән нәтиҗә ясый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы дәүләт телләре булган татар һәм рус телләрендә рәсми рәвештә бастырып чыгарганда тиешле срокларны үтәүнең кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау механизмының аерылгысыз элементы булганын һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләренең икесендә дә мәгълүмат алу конституциячел-хокукый гарантияләрен тулырак һәм эзлеклерәк тәэмин итүгә ярдәм итүен күрсәтеп китүне кирәк дип саный. Шуның белән бергә норматив хокукый актның тексты, аңа кушымта итеп бирелгән актларны да исәпкә алып, тулысынча татар телендә дә, рус телендә дә рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

3.2. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы беренче өлеше буенча күпфатирлы йорттагы милекчеләрнең гомуми җыелышы карары нигезендә башкарыла. Әлеге статьяның бишенче өлешендәге таләпләрдән күренгәнчә, бу карарда капи-

таль ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге; капиталь ремонтка дигән чыгымнар сметасы; капиталь ремонт ясау сроклары; капиталь ремонтны финанслау чыганаклары; капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итүдә күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләре исеменнән дә катнашырга, шул исәптән тиешле актларны имзаларга вәкаләтле булган зат билгеләнергә яки расланырга тиеш. Шуның белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүне федераль законнар нормалары мондый йорттагы урыннар милекчеләренең аерым хокукы дип карый.

Россия Федерациясе Торак кодексының 182 статьясы нигезләмәләре буенча күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлгән эш алып бара торган махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма (алга таба — төбәк операторы) төбәк операторы счетында капиталь ремонт фонды оештырган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре шундый йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итә. Төбәк операторы вәкаләтләренә шул исәптән төбәк капиталь ремонт программаларын һәм (яки) аларны гамәлгә ашыру буенча кыска вакытлы планнарны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары вәкилләре, шулай ук әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затлар һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре вәкилләре катнашы белән күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү комиссиясен төзүне тәэмин итү кертелгән.

Шуның белән бергә, Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы икенче өлешеннән аңлашылганча, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсе буенча төбәк операторының акча күчерүенә күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү акты нигез булып тора. Мондый кабул итү акты җирле үзидарә органы, шулай ук күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат белән килештерелгән булырга тиеш (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт шул күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре карары нигезендә үткәрелгән очракта).

Әлеге нигезләмәләрне дәвам итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәгъвалана торган Тәртип кабул ителгән, ул Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау төбәк программасы һәм, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан сайланган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау фондын формалаштыру ысулына бәйсез рәвештә, аны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнары нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итүнең гомуми кагыйдәләрен билгели, шулай ук капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү комиссиясен төзү һәм аның эшләү һәм капиталь ремонтлау буенча эшләрне ка-

бул иткәндә барлыкка килә торган каршылыкларны җайга салу тәртибен регламентлаштыра.

Шулай, Тәртипнең 2 бүлегендәге нигезләмәләреннән чыгып, капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүне капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү комиссиясе (алга таба — комиссия) составын раслаучы я төбәк операторы белән төзелгән шартнамә нигезендә техник заказчы функцияләре тапшырылган затлар (капиталь ремонтлау фондын төбәк операторы счетында, счетларында формалаштырган очракта), я махсус счет ияләре (капиталь ремонтлау фондын махсус счетта формалаштырган очракта) оештыра. Комиссия составына мәҗбүри тәртиптә күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләре исеменнән капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итәргә, шул исәптән тиешле актларны имзаларга вәкаләтле зат кертелә (2.1, 2.2, 2.3 пунктлар).

Тәртиптән күренгәнчә, капиталь ремонтлау буенча эшләр тулысынча тәмамланырга 10 эш көне кала подрядчы язма рәвештә техник заказчыга һәм махсус счет иясенә эшләрнең тулы күләмдә тәмамлануы һәм капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү кирәклеге турында хәбәр итә (3.4 пункт). Капиталь ремонтлау буенча эшләрнең кабул итүгә әзер булуы турында подрядчының язмача хәбәре нигезендә комиссия рәисе әлеге хәбәрне алган көннән соң өч эш көне эчендә күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү урынын һәм вакытын билгели һәм кабул итү датасына кимендә җиде эш көне кала комиссия әгъзаларына җиткерә (3.5 пункт). Капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсе яклары имзалаган һәм җирле үзидарә органы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика дәүләт торак күзәтчелеге вазыйфаларын башкаручы башкарма органы, төбәк операторы белән төзелгән төзелеш контролен гамәлгә ашыру шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма, күпфатирлы йорт белән идарәне гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук әгәр күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау бу күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре карары нигезендә башкарылган очракта, күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат белән килештерелгән беренчел исәп документларының КС-2 номерлы бердәм нормага китерелгән формасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү актлары, шулай ук беренчел исәп документларының КС-3 номерлы бердәм нормага китерелгән формасы буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар хакы турында белешмәләр нигезендә башкарыла.

Тәртипнең әлеге нигезләмәләренең сүзгә-сүз эчтәлеген анализлаудан, шулай ук аларның гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы урыннарын исәпкә алып, аларның максатлары белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча исемлеге күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең

капиталь ремонт ясау турында гомуми җыелышы карары белән алдан расланган фактта күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү процедурасын билгеләүгә юнәлгән булулары күренә.

Моннан тыш, Тәртипнең 3.9 пунктында каралганча, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул иткән вакытта комиссия әгъзасы кабул итү актына теркәлә торган искәрмәләр яки тәкъдимнәр күрсәтеп, үзенең аерым фикерен белдерә ала. Күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүгә комиссия әгъзаларының берсе каршы килсә, алар урында барлык комиссия әгъзалары тарафыннан карап тикшерелә һәм күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү мөмкинлеге яки мондый кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителә. Комиссия кабул иткән карарларга законнар нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин (3.12 пункт).

Шуның белән дәгъвалана торган Тәртип күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә ясалган капиталь ремонтның сыйфатын бәяләүне оештыру мәсьәләсендә бөтен комиссия әгъзалары өчен дә тигез хокуклар һәм бурычлар билгели һәм комиссия әгъзаларының күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү башланганчы капиталь ремонтка башкарма һәм техник документация белән танышып чыгуы өчен сроклар буенча нинди дә булса чикләүләр эченә алмый. Күпфатирлы йорттагы урыннарның барлык милекчеләре исеменнән капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашырга вәкаләтле затка карата бу аңа тиешле объектта эшләрне фактта башкару моментыннан алып, шул исәптән башкарылган эшләрне күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында расланган хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге һәм күләменә туры килү-килмәвен билгеләү максаты белән техник һәм башкарма документация белән танышу хокукы гарантияләнгәнен аңлата.

Шулай итеп, Тәртипнең дәгъвалана торган 3.7 пункты Тәртипнең югарыда китерелгән нигезләмәләре, шулай ук торак законнары нормалары белән аерылгысыз норматив берлектә тора һәм үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дә конституциячел хокукларын юкка чыгармый, киметми һәм башкача бозмый һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 2, 19 (беренче өлеш), 28 (беренче өлеш), 51 статьяларына каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Рес-

публикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 11 статьясын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенең 3.7 пунктын, шулай ук тулысынча аталган карарны аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип таныргa.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 74-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

ИМЕНЕМ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**по делу о проверке конституционности абзацев шестого, девятого и одиннадцатого пункта 2.5 графы «Содержание требования стандарта предоставления государственной услуги» раздела II Административного регламента предоставления государственной услуги по выдаче разрешения на осуществление сделок по отчуждению имущества, принадлежащего совершеннолетним лицам, признанным в судебном порядке недееспособными или ограниченно дееспособными (приложение № 6), утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 24 декабря 2013 года № 11787 «Об утверждении административных регламентов в сфере опеки и попечительства недееспособных или ограниченно дееспособных граждан» (в редакции постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 5 июня 2017 года № 2094), а также названного постановления в целом в связи с жалобой гражданина Р.С. Ибрагимова**

3 октября
2017 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

руководствуясь статьей 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан, частями пятой и девятой статьи 3, частью первой и пунктом 1 части второй статьи 39, статьями 68, 83, 100, 101 и 103 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан»,

рассмотрел в открытом судебном заседании дело о проверке конституционности абзацев шестого, девятого и одиннадцатого пункта 2.5 графы «Содержание требования стандарта предоставления государственной услуги» раздела II Административного регламента предоставления государственной услуги по выдаче разрешения на осуществление сделок по отчуждению имущества, принадлежащего совершеннолетним лицам, признанным в судебном порядке недееспособными или ограниченно дееспособными (приложение № 6), утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 24 декабря 2013 года № 11787 «Об утверждении административных регламентов в сфере опеки и попечительства недееспособных или ограниченно дееспособных граждан» (в редакции постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 5 июня 2017 года № 2094), а также названного постановления в целом по порядку его официального опубликования.

Поводом к рассмотрению дела явилась жалоба гражданина Р.С. Ибрагимова. Основанием к рассмотрению дела явилась обнаружившаяся неопределенность в вопросе о том, соответствуют ли оспариваемые заявителем нормативные положения Конституции Республики Татарстан.

Заслушав сообщение судьи-докладчика Л.В. Кузьминой, объяснения сторон — гражданина Р.С. Ибрагимова, представителя ор-

гана, издавшего оспариваемый нормативный правовой акт, — начальника отдела по вопросам финансового и трудового законодательства Правового управления аппарата Исполнительного комитета муниципального образования города Казани А.В. Токмакова, специалиста, приглашенного в судебное заседание по ходатайству представителя органа, издавшего оспариваемый нормативный правовой акт, — заместителя начальника отдела по опеке и попечительству Авиастроительного и Ново-Савиновского районов Исполнительного комитета муниципального образования города Казани Р.М. Шайхаттарова, выступления приглашенных в судебное заседание: представителя Президента Республики Татарстан — заведующего отделом правовой экспертизы Государственно-правового управления Президента Республики Татарстан М.В. Ляукина, представителя Государственного Совета Республики Татарстан — начальника Правового управления Аппарата Государственного Совета Республики Татарстан М.Б. Сунгатуллина, представителя Кабинета Министров Республики Татарстан — Правительства Республики Татарстан — начальника Правового управления Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан А.Б. Гревцова, представителя Председателя Верховного суда Республики Татарстан — судьи Верховного суда Республики Татарстан Э.С. Каминского, представителя Прокурора Республики Татарстан — начальника отдела по надзору за законностью нормативных правовых актов Управления по надзору за исполнением федерального законодательства прокуратуры Республики Татарстан А.Р. Валиахметова, представителя Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан — заместителя начальника отдела по вопросам восстановления прав граждан аппарата Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан Р.И. Сайфутдиновой, исследовав представленные документы и иные материалы, Конституционный суд Республики Татарстан

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин Р.С. Ибрагимов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод подпунктами 8, 11, 12, 13 и абзацем первым подпункта 14 пункта 2.5 графы «Содержание требования стандарта предоставления государственной услуги» раздела II Административного регламента предоставления государственной услуги по выдаче разрешения на осуществление сделок по отчуждению имущества, принадлежащего совершеннолетним лицам, признанным в судебном порядке недееспособными или ограниченно дееспособными (приложение № 6), утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 24 декабря 2013 года № 11787 «Об утверждении административных регламентов в сфере опеки и попечительства недееспособных или ограниченно дееспособных граждан» (далее также — Административный регламент), а также названным постановлением в целом по порядку его официального опубликования.

Пунктом 2.5 Административного регламента определен исчерпывающий перечень документов, необходимых для предоставления государственной услуги по выдаче разрешения на осуществление сделок по отчуждению имущества, принадлежащего совершеннолетним лицам, признанным в судебном порядке недееспособными или ограниченно дееспособными, в том числе: правоустанавливающие документы на отчуждаемое и приобретаемое имущество (подпункт 8); технический паспорт на отчуждаемое и приобретаемое недвижимое имущество (подпункт 11); справка БТИ (об оценочной стоимости) на отчуждаемое и приобретаемое недвижимое имущество (в случае отчуждения недвижимого имущества) (подпункт 12); финансовые лицевые счета и выписки из домовой книги жилой площади отдельно с места продажи и места покупки (обмена) жилых помещений (подпункт 13); справки об отсутствии задолженности отдельно с места продажи и места покупки (обмена) жилых помещений (абзац первый подпункта 14).

Как следует из содержания жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданин Р.С. Ибрагимов является опекуном своей родной сестры, инвалида I группы с детства, признанной в судебном порядке недееспособной, и зарегистрирован вместе с ней в квартире в городе Казани, в которой они имеют доли в праве собственности. Кроме того, у его подопечной имеется доля в праве собственности на дом в Сабинском муниципальном районе Республики Татарстан. До 2016 года он с сестрой проживал в городе Казани в индивидуальном жилом доме, в котором ему и его сестре принадлежит по $^1/_2$ доли в праве собственности на дом и земельный участок. Заявитель без разрешения органа опеки и попечительства снес указанный жилой дом, расположенный на данном земельном участке, с целью продажи земельного участка для покупки квартиры в строящемся доме по договору долевого участия в совместную со своей подопечной собственность. Для получения разрешения органа опеки и попечительства на продажу земельного участка он обратился по месту регистрации в отдел опеки и попечительства администрации Авиастроительного и Ново-Савиновского районов города Казани, где ему было отказано в выдаче указанного разрешения в связи с отсутствием документов на приобретаемое имущество, предусмотренных оспариваемыми нормами Административного регламента.

Гражданин Р.С. Ибрагимов считает требование отдела опеки и попечительства администрации Авиастроительного и Ново-Савиновского районов города Казани о необходимости получения разрешения необоснованным и отмечает, что он не мог представить в орган опеки и попечительства все требуемые документы в силу того, что некоторые из них относятся к вновь приобретаемой жилой площади, а дом, в котором он намеревается приобрести квартиру, еще находится в процессе строительства и заключить договор долевого участия в строительстве он сможет только после внесения необходимой суммы денег, полученной от продажи земельного участка.

По мнению заявителя, обжалуемые положения Администра-

тивного регламента применимы только при условии перемены места жительства подопечного, обязательно связанной с приобретением другого жилого помещения, что нарушает его конституционные права и свободы, а также конституционные права и свободы его подопечной.

Кроме того, гражданин Р.С. Ибрагимов полагает, что с нарушением была осуществлена и процедура опубликования обжалуемого постановления, так как оно не было официально опубликовано на татарском языке, что также нарушает его конституционные права.

полномочий, закрепил право бесплатного предоставления земельных участков в собственность гражданам, имеющим трех и более детей, постоянно проживающим на территории Республики Татарстан, для осуществления в том числе индивидуального жилищного строительства (пункт 3 статьи 32). При этом республиканский законодатель, устанавливая механизм реализации такого права, принял во внимание и положения Методических рекомендаций субъектам Российской Федерации по порядку и случаям бесплатного предоставления земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, утвержденных приказом Министерства регионального развития Российской Федерации от 9 сентября 2013 года № 372 (далее также — Методические рекомендации), согласно которым в законах субъектов Российской Федерации, устанавливающих случаи и порядок бесплатного предоставления гражданам, имеющим трех и более детей, земельных участков, рекомендуется определить в том числе полномочие органов местного самоуправления по ведению адресного перечня земельных участков, предназначенных для предоставления таким гражданам, имеющим трех и более детей, на территории муниципального образования (подпункт 5 пункта 21).

Так, оспариваемыми положениями статьи 32.1 Кодекса установлен порядок бесплатного предоставления земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, в частности, порядок формирования органами местного самоуправления перечней земельных участков с учетом потребности, определяемой исходя из списков граждан, имеющих право на получение данных земельных участков (пункт 8); порядок формирования и ведения таких списков органом местного самоуправления раздельно в соответствии с целями предоставления земельных участков и определения очередности граждан по дате и времени подачи заявления (пункт 11); срок предоставления гражданам земельных участков и порядок проведения процедуры выбора земельных участков (пункт 13).

Из буквального содержания обжалуемых положений следует, что они устанавливают последовательность действий органов местного самоуправления по исполнению законодательно установленных правовых норм, направленных на реализацию гражданами, имеющими трех и более детей, своего права на бесплатное получение земельного участка. При этом, возлагая на органы местного самоуправления полномочия по установлению процедуры предоставления таких земельных участков, республиканский законодатель четко и недвусмысленно определил обязательные для этого условия. Применительно к формированию перечня земельных участков одним из таких условий выступает потребность в земельных участках, которая определяется исходя из списков граждан, имеющих право на их получение, формируемых в зависимости от даты и времени подачи ими заявления.

Тем самым оспариваемые заявителями нормы Земельного кодекса Республики Татарстан по своему смыслу и содержанию определяют организационно-правовой механизм предоставления меры

социальной поддержки для многодетных семей, имеющих трех и более детей, и направлены на удовлетворение их потребностей в земельных участках, как семей, находящихся потенциально в наиболее уязвимом социальном положении и нуждающихся в особой заботе со стороны государства и общества в силу конституционных принципов равенства и справедливости. Рассматриваемые пункты 8, 11 и 13 статьи 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан находятся в системном единстве, по своему целевому назначению направлены на упорядочивание процедуры бесплатного предоставления земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, а также предопределяют для органов местного самоуправления четкий перечень полномочий в данной сфере, в том числе по принятию соответствующих нормативных правовых актов, что само по себе не допускает введения органами местного самоуправления дополнительных условий предоставления конкретных земельных участков на территории соответствующего муниципального образования, помимо тех, которые предусмотрены исчерпывающим образом в акте, имеющем большую юридическую силу.

Таким образом, обжалуемые законодательные нормы исключают любое иное их истолкование в правоприменительной практике, не отменяют, не умаляют и иным образом не нарушают конституционные права человека и гражданина, в том числе права заявителей, и, следовательно, не противоречат статьям 28 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая), 38 (части первая и третья), 55 и 58 Конституции Республики Татарстан.

3.2. Как указывал Конституционный Суд Российской Федерации в своих решениях, конституционная природа местного самоуправления как публичной власти, наиболее приближенной к населению и ориентированной в том числе на выполнение задач социального государства, связанных с непосредственным обеспечением жизнедеятельности населения муниципальных образований, обусловливает необходимость учета особенностей данной публичной власти; это предопределяет необходимость достижения баланса таких конституционно защищаемых ценностей, как самостоятельность местного самоуправления в пределах своих полномочий, с одной стороны, и гарантированность гражданам соответствующих социальных прав, включая права, приобретенные на основании закона, независимо от того, на территории какого муниципального образования они проживают, — с другой (постановления от 11 ноября 2003 года № 16-П, от 15 мая 2006 года № 5-П, от 18 мая 2011 года № 9-П, от 5 июля 2017 года № 18-П и др.).

Данная правовая позиция, применительно к рассматриваемому делу, предопределяет содержание и смысл в том числе актов органов местного самоуправления, регламентирующих порядок формирования перечня земельных участков, бесплатно предоставляемых многодетным семьям, имеющим трех и более детей, постоянно проживающим на территории определенного муниципального образования, для осуществления индивидуального жилищного строительства.

Приводимые заявителями доводы свидетельствуют о том, что нарушение своих конституционных прав они связывают с наличием непосредственно в тексте оспариваемых абзацев девятого и десятого Перечня указания на дополнительные условия предоставления предусмотренных в этих абзацах конкретных земельных участков, расположенных в пределах территории муниципального образования города Казани, для отдельных категорий многодетных семей в зависимости от количества детей (пять и более, четверо и более соответственно), что препятствует многодетным семьям с тремя детьми реализовать свое право на получение данных земельных участков.

Конституционный суд Республики Татарстан со ссылкой на правовые позиции Конституционного Суда Российской Федерации уже отмечал, что как федеральное, так и республиканское законодательство не закрепляет единого понятия многодетной семьи. При этом нормативное содержание понятия «семья» наполняется в зависимости от целей правового регулирования различным юридическим содержанием (постановление от 5 октября 2011 года № 44-П).

Применительно к рассматриваемой сфере правоотношений Земельным кодексом Российской Федерации прямо установлено, что земельные участки, находящиеся в государственной или муниципальной собственности, предоставляются бесплатно гражданам, имеющим трех и более детей, в случае и в порядке, которые установлены органами государственной власти субъектов Российской Федерации (подпункт 6 статьи 39.5). В рамках предоставленных полномочий республиканский законодатель установил в Земельном кодексе Республики Татарстан, что под гражданами, имеющими трех и более детей, понимается многодетная семья (абзац четвертый пункта 3 статьи 32). При этом в качестве правовых условий для предоставления земельных участков многодетным семьям республиканский законодатель определил лишь факт их постоянного проживания на территории Республики Татарстан, а также хронологический принцип формирования очередности постановки их на учет.

Анализ оспариваемых положений Перечня показывает, что Исполнительный комитет муниципального образования города Казани определил предоставление указанных в них земельных участков лишь многодетным семьям, имеющим четверых и более и пять и более детей. По своему правовому смыслу их содержание фактически устанавливает дополнительные условия, в силу которых реализовать право на получение данной меры социальной поддержки непосредственно на территории муниципального образования города Казани могут только отдельные категории многодетных семей.

Однако согласно приведенным выше нормам федерального и республиканского земельного законодательства все многодетные семьи имеют равный доступ на бесплатное получение земли независимо как от количества детей в таких семьях, так и от места расположения земельных участков. Органы местного самоуправ-

ления, в том числе Исполнительный комитет муниципального образования города Казани, могут определить лишь перечень земельных участков (расположение и площадь), предназначенных для выделения многодетным семьям, которые будут формироваться и распределяться между всеми ними в зависимости только от очередности подачи соответствующих заявлений. Установление же преимущественного права отдельным категориям многодетных семей в Республике Татарстан является исключительной прерогативой органов государственной власти и выходит за рамки полномочий органов местного самоуправления. На это указано и в Методических рекомендациях, в пункте 8 которых прямо предусмотрено, что условия для предоставления гражданам, имеющим трех и более детей, земельных участков могут быть установлены законами субъекта Российской Федерации в том числе дифференцированно, исходя из сложившейся в субъектах Российской Федерации социально-экономической и демографической ситуации.

Следовательно, органы местного самоуправления, как наиболее приближенные к населению органы публичной власти, при осуществлении соответствующего правового регулирования, равно как и при определении конкретных земельных участков, должны обеспечивать равный подход в реализации законодательно установленного права в отношении формально равных субъектов — многодетных семей, имеющих трех и более детей.

В этой связи наличие в обжалуемых абзацах Перечня дополнительных условий предоставления многодетным семьям земельных участков в зависимости от количества детей в семье нарушает принципы верховенства закона, равенства и справедливости, поддержания доверия граждан к закону и действиям государства, а также посягает на само существо предоставленного гражданам, имеющим только трех детей, права на государственную поддержку в виде бесплатного предоставления земельного участка в собственность непосредственно на территории муниципального образования города Казани.

Таким образом, Конституционный суд Республики Татарстан приходит к выводу, что абзацы девятый и десятый Перечня земельных участков, бесплатно предоставляемых многодетным семьям, постоянно проживающим на территории муниципального образования города Казани, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 18 ноября 2013 года № 9838 (в редакции от 6 июля 2016 года), содержащие дополнительные условия предоставления многодетным семьям конкретных земельных участков в зависимости от количества детей в многодетной семье, не соответствуют статьям 10, 24 (части первая и вторая), 28 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая), 38 (части первая и третья), 55, 58 и 116 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

На основании изложенного, руководствуясь статьями 6, 63, частями первой и второй статьи 66, статьями 67, 68, 69, 71, 73 и 104 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**постановил:**

1. Признать пункты 8, 11 и 13 статьи 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан соответствующими Конституции Республики Татарстан.

2. Признать абзацы девятый и десятый Перечня земельных участков, бесплатно предоставляемых многодетным семьям, постоянно проживающим на территории муниципального образования города Казани, для осуществления индивидуального жилищного строительства, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 18 ноября 2013 года № 9838 (в редакции от 6 июля 2016 года), в части установления в них дополнительных условий предоставления многодетным семьям конкретных земельных участков в зависимости от количества детей в многодетной семье не соответствующими Конституции Республики Татарстан.

3. Настоящее Постановление окончательно, не подлежит обжалованию, вступает в силу немедленно после его провозглашения, действует непосредственно и не требует подтверждения другими органами и должностными лицами.

4. Согласно статье 72 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» настоящее Постановление подлежит незамедлительному опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан» и «Республика Татарстан». Постановление должно быть опубликовано также в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 77-П

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИСЕМЕ БЕЛӘН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова шикаятьләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктларының һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең тугызынчы һәм унынчы абзацларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

2017 ел
26 декабрь
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктларының һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең тугызынчы һәм унынчы абзацларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова шикаятьләре сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Шикаятьләр бер үк предметка кагылышлы булганга күрә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 50 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге шикаятьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерде.

Докладчы судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын, яклар — гражданнар О.Н. Меркурьева һәм Л.В. Рагимова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге мөдире И.И. Фәттахов, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты хокукый тәэмин итү бүлеге баш белгече Е.Н. Ситдыйкова, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты җир кишәрлекләренә хокукларны рәсмиләштерүгә аналитик ярдәм һәм социаль мәсьәләләр бүлеге башлыгы А.Р. Сафина аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Р.В. Сидаков, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы М.М. Сафина, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлегенең әйдәүче консультанты Р.Р. Мингалиев чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова Татарстан Республикасы Җир кодексының (алга таба шулай ук — Кодекс) 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктлары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең (алга таба шулай ук — Исемлек) тугызынчы һәм унынчы абзацлары белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр.

Кодексның 32.1 статьясындагы 8 пунктында билгеләнгәнчә, өч һәм аннан күбрәк баласы булган, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче гражданнарга индивидуаль то-

рак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен бирүгә билгеләнгән җир кишәрлекләре исемлекләре Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры белешмәләре нигезендә, әлеге җир кишәрлекләрен алу хокукы булган гражданнар исемлекләреннән чыгып билгеләнә торган ихтыяҗны исәпкә алып, Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелә. Җир кишәрлекләре исемлекләре аларның бирелү максатлары нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан һәркайсына аерым төзелә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Әлеге Кодексның 32.1 статьясындагы 11 пункты күздә тотканча, өч һәм аннан күбрәк баласы булган, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче гражданнардан гариза кергән көннән башлап 30 көн эчендә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы мөрәҗәгать итүчене индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен җир кишәрлеге алу хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертү турында карар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүчегә уникаль исәпкә алу номеры бирә. Исемлекләр булдыруны һәм алып баруны җирле үзидарә органы җир кишәрлекләренең бирелү максатлары нигезендә һәркайсы буенча аерым гамәлгә ашыра. Гражданнарның чираты гариза бирелү көне һәм вакыты буенча билгеләнә. Гражданнарның уникаль исәпкә алу номерлары исемлекләре, чиратлылык күрсәтелеп, «Интернет» челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырыла һәм гражданнарны исемлекләргә керткән саен һәм аларга җир кишәрлекләре бирелгән саен яңартылырга тиеш.

Югарыда күрсәтелгән Кодексның 32.1 статьясындагы 13 пункты билгеләгәнчә, индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен гражданнарга җир кишәрлекләре бирү аларны исемлекләргә керткән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә гамәлгә ашырыла. Җирле үзидарә органнары җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын уздыру урынын, көнен һәм вакытын билгелиләр һәм гражданнарны чиратлылык һәм табылган җир кишәрлекләре саны нигезендә әлеге процедурада катнашу өчен билгелиләр. Җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән гражданнарга җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы уздырыла торган көнгә кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча аны уздыру урыны, датасы, вакыты турында адресатка тапшырылуы хакында белдерү кәгазе булган заказлы хат, телеграмма яисә, имза куйдырып, хәбәрнамә тапшыру юлы белән хәбәр итәлә. Җир кишәрлекләре исемлегеннән гражданнар тарафыннан җир кишәрлеген сайлап алу чиратлылык нигезендә гамәлгә ашырыла, һәм бу хакта акт төзелә, ул мөрәҗәгать итүче

һәм җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан имзалана.

Исемлекнең тугызынчы һәм унынчы абзацлары белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре билгеләнгән, атап әйткәндә: Казан шәһәренең Совет районындагы Константиновка торак массивыннан төньяк-көнбатыштарак урнашкан, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга бирү өчен билгеләнгән территория һәм Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы Зур Дербышки һәм Щербаково торак массивлары арасында урнашкан, дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга бирү өчен билгеләнгән территория.

Шикаятьләрдән һәм аларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова — өч баласы булган күпбалалы аналар. Мөрәҗәгать итүчеләр 2013—2014 елларда индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен аларны исемлекләргә керткән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча бирелергә тиешле җир кишәрлеген түләүсез алуга хокуклары булган гражданнар исемлегенә кертелгән булганнар. Ләкин, алар күрсәткәнчә, Казан шәһәрендә өч баласы гына булган гаиләләргә җир кишәрлекләре фактта бирелми, чөнки, алар фикеренчә, дәгъвалана торган Исемлектә күпбалалы гаиләдәге бала санына карап, җир кишәрлекләрен бирүдә төрле алым кулланыла. Шулай, Казан шәһәреннән читтә урнашкан җир кишәрлекләре (Исемлекнең беренче—сигезенче абзацлары) бөтен күпбалалы гаиләләр өчен каралган, ә Казан шәһәре чикләрендәге җир кишәрлекләре бары тик биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләр (Исемлекнең тугызынчы абзацы) һәм дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләр (Исемлекнең унынчы абзацы) өчен каралган.

Гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен гариза бирелү көне һәм вакыты буенча чиратлылык тәртибендә бирү шарты Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясында инде билгеләнгән һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан күпбалалы гаиләдәге бала саныннан чыгып үзгәртелә алмый дип саныйлар. Ләкин, алар билгеләгәнчә, Исемлекнең дәгъвалана торган тугызынчы һәм унынчы абзацларында күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала саныннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар билгеләүче норматив нигезләмәләр бар, бу исә юридик тигезлек һәм хокук өстенлеге конституциячел принципларына каршы килә.

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчеләр күрсәтелгән Кодексның 32.1 статьясындагы 8 пункты җирле үзидарә органнарына җир кишәрлекләренең тиешле исемлекләрен булдыру вәкаләтен биреп, алар тарафыннан бары тик территорияләрне билгели торган һәм нинди дә булса гомуми кагыйдәләрсез һәм конкретлаштыру-

чы норматив күрсәтмәләрсез норматив булмаган хокукый актлар кабул итүне күздә тота дип саныйлар. Алар фикеренчә, әлеге Кодексның 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктлары җирле үзидарә органнарының җир кишәрлекләре исемлекләрен булдырганда күпбалалы гаиләләрнең конкрет җир кишәрлекләренең урнашу урынын сайлавын андый гаиләләрдәге бала саны белән бәйләргә хокуклы түгел икәнлеген тулы ачыклык белән билгеләмиләр.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктларын һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең тугызынчы һәм унынчы абзацларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорыйлар, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела; Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклауның тигез хокукы гарантияләнә; гаилә, ана булу, ата булу һәм балачак дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында кайгырта; һәркем торакка хокуклы, беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар; Татарстан Республикасы Конституциясендә төп хокукларны һәм ирекләрне санап чыгу кешенең һәм гражданның гомумтанылган башка хокукларын һәм ирекләрен кире кагу һәм киметү буларак аңлатылмаска тиеш; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 21 декабрендәге 5323 номерлы карары белән Исемлекнең дәгъвалана торган нигезләмәләреннән күпбалалы гаиләләргә күрсәтелгән җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала санынннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар юкка чыгарылган.

Әмма бу хәл үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан мөрәҗәгать итүчеләр дәгъва белдерә торган нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерүгә кертә

була алмый, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлеше нигезендә конституциячеллеге дәгъваланучы акт юкка чыгарылган булса яисә эшне карый башлаганчы я аны карау чорында үз көчен югалткан булса, Татарстан Республикасы Конституция суды башлаган эш туктатылырга мөмкин, моңа бу актның гамәлдә булуы аркасында гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылган очраклар керми.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктлары алар нигезендә гамәлдәге хокукый җайга салу системасында җирле үзидарә органнары тарафыннан күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләрен түләүсез бирүнең өстәмә шартлары билгеләнүгә юл куела торган дәрәҗәдә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала саныннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар булган тугызынчы һәм унынчы абзацлары әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм җир законнары өлкәләренә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук җир законнары Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясында каралганча, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла (2 өлеш); Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча, шулай ук Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының

уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул ителгән федераль законнарга каршы килә алмый (5 өлеш).

Җир законнары Россия Федерациясе Җир кодексыннан, федераль законнардан һәм аларга ярашлы кабул ителә торган Россия Федерациясе субъектлары законнарыннан тора (Россия Федерациясе Җир кодексының 2 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацы). Әлеге Кодексның 39.5 статьясындагы 6 пунктчасы белән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар милкенә вәкаләтле органның карары нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә түләүсез бирелә дип билгеләнгән. Шул ук вакытта әлеге Кодекс, федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә һәм шуларны үтәү йөзеннән җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә җир хокукы нормаларын үз эченә алган актлар чыгара ала (2 статьяның 4 пункты).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты белән шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә шәһәр округының муниципаль милкендәге мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү кертелгән.

Эчтәлеге буенча тиңдәш нормалар Татарстан Республикасы Җир кодексының 5 статьясындагы 2 пунктчасы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 8 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты белән беркетелгән.

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы беренче өлеше, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясындагы беренче өлеше белән үзара бәйләнештә 40 статьясындагы икенче өлешенең 4 абзацы буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, шул исәптән җирле үзидарә органнарының җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләренә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Җир кодексы, башка федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән кертелгән мәсьәләләрне хәл итү йөкләнгән Казан шәһәре җирле үзидарәсенең башкарма-күрсәтмә органы булып тора.

Шулай итеп, дәгъвалана торган норматив хокукый актларны кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты федераль һәм республика законнары нигезендә үзләренә бирелгән вәкаләтләрен

законлы рәвештә гамәлгә ашырганнар, әлеге вәкаләтләр Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйләнештәге 75 (2 пункт) һәм 116 (беренче өлеш) статьяларына нигезләнгән, алар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләрне һәм Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрне Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә закон чыгарып җайга салу керә; җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә.

3. Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), Татарстан Республикасы Конституциясе шуны беркетә: гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында, дәүләт гаилә турында кайгырта (38 статья, беренче һәм өченче өлешләр); һәркемгә шул исәптән балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш); җир һәм башка табигать ресурслары хосусый, дәүләти, муниципаль милектә һәм милекнең башка рәвешләрендә булырга мөмкин (18 статья, икенче өлеш). Мәгънәләре буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 9 (2 өлеш), 36 (1 өлеш), 38 (1 өлеш) һәм 39 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе кебек үк, җир кишәрлекләрен түләүсез бирүгә хокукны гарантияләми. Җир законнарының төп принципларын билгеләп, Россия Федерациясе Җир кодексы шул исәптән җирдән файдалануның түләүлелеге принцибын бүлеп чыгара, аның буенча, федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары билгеләгән очраклардан тыш, җирдән теләсә нинди файдалану түләүле башкарыла (1 статьяның 1 пунктындагы 7 пунктчасы).

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе буенча гаиләгә, ана һәм ата булуга, балачакка дәүләт ярдәмен тормышка ашыруның конкрет юнәлешләрен һәм чараларын билгеләү дискрециясенә ия булган закон чыгаручы, аерым алганда, шундый ярдәмне оештыру максатында дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан индивидуаль торак төзелешенә ярдәм итү мөмкинлекләрен шул исәптән моның өчен гражданнарның аерым категорияләренә җир кишәрлекләрен милек итеп түләүсез бирү һәм шуның белән торакка хокукны гамәлгә ашыруның өстәмә шартларын булдыру юлы белән кулланырга хокуклы (2017 елның 9 ноябрендәге 2516-О номерлы Билгеләмә).

3.1. Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясы нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү очраклары арасында җир кишәрлеген өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар милкенә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә түләүсез бирү каралган (6 пунктча).

Татарстан Республикасында күрсәтелгән хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Җир кодексында чагылыш тапкан, анда, үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә эш итеп, закон чыгаручы җир кишәрлекләрен өч һәм аннан күбрәк баласы булган, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче гражданнар милкенә шул исәптән индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен түләүсез бирү хокукын беркеткән (32 статьяның 3 пункты). Шул ук вакытта, андый хокукны тормышка ашыру механизмын билгеләп, республика закон чыгаручысы Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2013 елның 9 сентябрендәге 372 номерлы боерыгы белән расланган Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү тәртибе һәм очраклары буенча Россия Федерациясе субъектларына методик тәкъдимнәр (алга таба шулай ук — Методик тәкъдимнәр) нигезләмәләрен дә игътибарга алган, алар буенча Россия Федерациясе субъектларының өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү очракларын һәм тәртибен билгели торган законнарында шул исәптән җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлек территориясендә өч һәм аннан күбрәк баласы булган шундый гражданнарга бирү өчен каралган җир кишәрлекләренең адреслы исемлеген алып бару буенча вәкаләтен билгеләргә тәкъдим ителә (21 пунктның 5 пунктчасы).

Шулай, Кодексның 32.1 статьясындагы дәгъвалана торган нигезләмәләре белән өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү тәртибе, аерым алганда, әлеге җир кишәрлекләрен алу хокукы булган гражданнар исемлекләреннән чыгып билгеләнә торган ихтыяҗны исәпкә алып, җирле үзидарә органнары тарафыннан җир кишәрлекләре исемлеген булдыру тәртибе (8 пункт); җир кишәрлекләренең бирелү максатлары нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан һәркайсы буенча аерым шундый исемлекләр булдыру һәм алып бару һәм гражданнарның чиратын гариза бирелү көне һәм вакыты буенча билгеләү тәртибе (11 пункт); гражданнарга җир кишәрлекләрен бирү срогы һәм җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын уздыру тәртибе (13 пункт) билгеләнгән.

Дәгъвалана торган нигезләмәләрнең сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, алар өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарның җир кишәрлеген түләүсез алу хокукын гамәлгә ашыруга юнәлгән законнарда билгеләнгән хокукый нормаларны үтәү буенча җирле үзидарә органнарының гамәлләре эзлеклелеген билгелиләр. Шул ук вакытта, шундый җир кишәрлекләрен бирү процедурасын билгеләү вәкаләтләрен җирле үзидарә органнарына йөкләп, республика закон чыгаручысы моның өчен мәҗбүри булган шартларны ачык һәм төгәл билгеләгән. Җир кишәрлекләре исемлеген булдыруга карата шундый шартларның берсе булып җир кишәрлекләренә ихтыяҗ тора, әлеге ихтыяҗ аларны алырга хокукы булган гражданнарның гариза бирелү көне һәм вакытына карап булдырыла торган исемлекләреннән чыгып билгеләнә.

Шуның белән Татарстан Республикасы Җир кодексының мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъвалана торган нормалары үзләренең мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча өч һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чарасы күрсәтүнең оештыру-хокукый механизмын билгелиләр һәм аларның потенциаль аеруча киеренке социаль хәлдә торган һәм тигезлек һәм гаделлек конституциячел принциплары нигезендә дәүләт белән җәмгыятьнең аерым кайгыртуына мохтаҗ булган гаиләләр буларак җир кишәрлекләренә ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлгән. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы карала торган 8, 11 һәм 13 пунктлары системалы берлектә торалар, үзләренең максатчан билгеләнеше буенча өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү процедурасын җайга салуга юнәлгәннәр, шулай ук җирле үзидарә органнары өчен әлеге өлкәдә шул исәптән тиешле норматив хокукый актлар кабул итү буенча вәкаләтләрнең төгәл исемлеген күздә тоталар, бу үзеннән-үзе тиешле муниципаль берәмлек территориясендә конкрет җир кишәрлекләре бирүнең зуррак юридик көчкә ия булган актта тулы рәвештә каралганнардан үзгә өстәмә шартларын җирле үзидарә органнары тарафыннан кертүне рөхсәт итми.

Шулай итеп, дәгъвалана торган закон нормалары хокук куллану практикасында аларның башка төрле аңлатылуына юл куймыйлар, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 55 һәм 58 статьяларына каршы килмиләр.

3.2. Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында күрсәткәнчә, җирле үзидарәнең халыкка иң якын булган һәм шул исәптән муниципаль берәмлекләрдәге халыкның көнкүрешен турыдан-туры тәэмин итү белән бәйле социаль дәүләт бурычларын үтәүгә юнәлгән гавами хакимият буларак конституциячел табигате әлеге гавами хакимият үзенчәлекләрен исәпкә алу кирәклеген китереп чыгара; бу, бер яктан, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйльлеге һәм, икенче яктан, гражданнарга, аларның нинди муниципаль берәмлек территориясендә яшәүләренә карамастан, закон нигезендә алынган хокукларны кертеп, тиешле социаль хокукларны гарантияләү кебек конституциячел яклана торган кыйммәтләр балансын булдыру кирәклеген күздә тота (2003 елның 11 ноябрендәге 16-П номерлы, 2006 елның 15 маендагы 5-П номерлы, 2011 елның 18 маендагы 9-П номерлы, 2017 елның 5 июлендәге 18-П номерлы һ.б. карарлар).

Тикшерелә торган эшкә карата әлеге хокукый позиция шул исәптән җирле үзидарә органнарының өч һәм аннан күбрәк баласы булган, аерым муниципаль берәмлек территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен түләүсез бирелә торган җир кишәрлекләре

исемлеген булдыру тәртибен регламентлаштыра торган актларының эчтәлеге һәм мәгънәсенә нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан китерелә торган дәлилләр шуны күрсәтәләр: үзләренең конституциячел хокукларының бозылуын алар турыдан-туры исемлекнең дәгъвалана торган тугызынчы һәм унынчы абзацлары текстында әлеге абзацларда каралган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә урнашкан конкрет җир кишәрлекләрен күпбалалы гаиләләрнең аерым категорияләренә бала санына карап (тиешенчә биш һәм аннан күбрәк, дүрт һәм аннан күбрәк) бирүнең өстәмә шартлары булу белән бәйлиләр, бу исә өч балалы күпбалалы гаиләләргә әлеге җир кишәрлекләрен алуга хокукларын тормышка ашыруга комачаулый.

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позицияләрен кулланып, Татарстан Республикасы Конституция суды федераль законнарда да, республика законнарында да күпбалалы гаиләнең бердәй төшенчәсе күрсәтелми дип билгеләгән иде инде. Монда «гаилә» төшенчәсенең норматив эчтәлеге хокукый җайга салу максатларыннан чыгып төрле юридик эчтәлек белән баетыла (2011 елның 5 октябрендәге 44-П номерлы карар).

Тикшерелә торган хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсенә карата Россия Федерациясе Җир кодексы белән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә түләүсез бирелә дип турыдан-туры билгеләнгән (39.5 статьяның 6 пунктчасы). Бирелгән вәкаләтләр кысаларында республика закон чыгаручысы Татарстан Республикасы Җир кодексында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар буларак күпбалалы гаилә танылa дип билгеләгән (32 статьяның 3 пунктындагы дүртенче абзацы). Шул ук вакытта күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бирү өчен хокукый шартлар буларак республика закон чыгаручысы бары тик аларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын, шулай ук аларны исәпкә кую буенча чиратлылыкны хронологик принципта булдыруны билгеләгән.

Исемлекнең дәгъвалана торган нигезләмәләренә анализ Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аларда күрсәтелгән җир кишәрлекләрен бары тик дүрт һәм аннан күбрәк, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләргә генә бирүне билгеләгән дип күрсәтә. Үзенең хокукый мәгънәсе буенча аларның эчтәлеге фактта өстәмә шартлар билгели, алар нигезендә социаль ярдәмнең әлеге чарасы күрсәтелүгә хокукны турыдан-туры Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күпбалалы гаиләләрнең бары тик аерым категорияләре генә тормышка ашырырга мөмкин.

Ләкин федераль һәм республика җир законнарының югарыда китерелгән нормалары нигезендә бөтен күпбалалы гаиләләр андый гаиләләрдәге бала санына да, шулай ук җир кишәрлекләренең урнашу урынына да бәйсез рәвештә җирне түләүсез

алу мөмкинлегенә тигез рәвештә ия. Җирле үзидарә органнары, шул исәптән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты күпбалалы гаиләләргә бирү өчен каралган җир кишәрлекләре исемлеген (урнашу урыны һәм мәйданы) генә билгели алалар, алар тиешле гаризаларны бирү чиратлылыгына гына бәйле рәвештә булдырылачак һәм бөтенесе арасында бүленәчәк. Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең аерым категорияләре өчен өстенлекле хокук билгеләү дәүләт хакимияте органнарының аерым хокукы булып тора һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләре чикләреннән чыга. Моңа Методик тәкъдимнәрдә дә күрсәтелгән, аларның 8 пунктында турыдан-туры шул күздә тотылган: өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен бирү өчен шартлар, Россия Федерациясе субъектларындагы социаль-икътисади һәм демографик ситуациядән чыгып, Россия Федерациясе субъекты законнары белән шул исәптән дифференциацияләнгән рәвештә билгеләнергә мөмкин.

Димәк, җирле үзидарә органнары, халыкка иң якын булган гавами хакимият органнары буларак, тиешле хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда, шулай ук конкрет җир кишәрлекләрен билгеләгәндә дә формаль яктан тигез субъектлар — өч һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр мөнәсәбәтендә законнарда билгеләнгән хокукны тормышка ашыруда тигез алымны тәэмин итәргә тиешләр.

Шуңа бәйле рәвештә Исемлекнең дәгъвалана торган абзацларында күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре гаиләдәге бала санына карап бирелә дигән өстәмә шартлар булу закон өстенлеге, тигезлек һәм гаделлек, законга һәм дәүләт гамәлләренә гражданнарның ышанычын саклау принципларын боза, шулай ук өч баласы гына булган гражданнарга турыдан-туры Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлеген милеккә түләүсез тапшыру рәвешендә бирелгән дәүләт ярдәменә хокукның асылына кагыла.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды шундый нәтиҗәгә килә: Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала саныннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар булган тугызынчы һәм унынчы абзацлары Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 24 (беренче һәм икенче өлешләр), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 55, 58 һәм 116 (беренче өлеш) статьяларына туры килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлеш-

ләренә, 67, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктларын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең тугызынчы һәм унынчы абзацларын аларда күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала саныннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар билгеләнгән өлештә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 77-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карары нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирү мәсьәләсе Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде, ул күрсәтелгән түләү үзенең хокукый табигате буенча федераль законнар нормаларына нигезләнеп билгеләнә торган социаль яклау чаралары исәбенә керми дип билгеләде. Бу түләү федераль законнарда аналогы булмаган өстәмә социаль ярдәм чарасы булып тора, аны билгеләү «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы булып тора һәм, барыннан да элек, Татарстан Республикасының финанс мөмкинлекләре белән билгеләнә. Димәк, әлеге түләүне бирү шартлары һәм күләме, бу түләүләрне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы бюджетының реаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә, бу исә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче өлеше эчтәлегеннән килеп чыга (2012 елның 4 июлендәге 49-П номерлы карар).

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентацияләүне сайлап алганда җитәрлек дәрәҗәдә иркле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар; 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 9.5 һәм 9.8 пунктлары үзара бәйләнештә торалар һәм үзләренең эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне билгеләү һәм исәпләүнең оештыру-процедура механизмы булып торалар һәм аның күләмен һәм түләү периодын исәпләүнең нинди дә булса өстәмә нигезсез шартларын билгеләмиләр.

Шулай, әлеге период өчен уртача айлык керем турындагы мәгълүматны исәпкә алып, акчалата түләүләр күләме үзгәртелергә тиеш булмаган алты айлык вакыт социаль ярдәм чараларын билгеләү өчен федераль һәм республика законнарында кулланыла («Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 14 декабрендәге 761 номерлы карарының 32 пункты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.3.1 пункты).

Мондый алым гражданнарга артырга да, кимергә дә мөмкин булган уртача айлык керемнәренең үзгәрүенә бәйсез рәвештә билгеләнгән период эчендә түләүне бер үк күләмдә алу мөмкинлеген тигез дәрәҗәдә гарантияләргә ирек бирә.

Шулай итеп, Нигезләмәнең карала торган нормалары үзләреннән-үзе гражданнарның конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмыйлар һәм, димәк, аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Нигезләмәнең 9.3 пунктында һәм 9.4 пунктындагы беренче абзацында сылтама ясалган 9.11 пунктның Нигезләмә текстында булмавы мәсьәләсенә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды шуңа игътибар итә: «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 20 декабрендәге 959 номерлы карары белән билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә «9.9—9.11» пунктларны тиешенчә «9.8—9.10» пунктлар дип санарга (1 пунктның алтынчы абзацы). Моны исәпкә алып, Нигезләмәнең гражданка Г.П. Луговнина тарафыннан дәгъвалана торган 9.3 пунктында һәм 9.4 пунктының беренче абзацында 9.11 пунктына сылтамаларны күрсәтелгән Нигезләмәнең 9.10 пунктына сылтамалар дип санарга кирәк. Шуңа бәйле рәвештә дәгъвалана торган нигезләмәләрдә аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Ләкин бу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын аның тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларга үзгәрешләр керткәндә юридик техника кагыйдәләрен үтәүдән азат итми. Шулай итеп, мөрәҗәгать итүченең шикаяте Нигезләмәнең конституциячеллеген аны бастырып чыгару формасы буенча тикшерү өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Респуб-

ликасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә шулай ук карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72 һәм 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 22 июнендәге 425 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.3 пункты, 9.4 пунктындагы беренче абзацы, 9.5 пунктындагы беренче абзацының аерым нигезләмәләре һәм 9.8 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Луговнина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.П. Луговнинага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 24-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

10 июля
2017 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Р.К. Галимова на нарушение его конституционных прав и свобод статьей 32 Земельного кодекса Республики Татарстан**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина Р.К. Галимова,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин Р.К. Галимов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод статьей 32 Земельного кодекса Республики Татарстан.

Оспариваемая норма регулирует вопросы предоставления земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, в собственность граждан и юридических лиц, в том числе устанавливает случаи предоставления таких земельных участков бесплатно.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявитель является участником ликвидации последствий катастрофы на Чернобыльской АЭС в 1988 году. Гражданин Р.К. Галимов отмечает, что нуждается в улучшении жилищных условий и в соответствии с пунктом 8 части первой статьи 14 Закона Российской Федерации от 15 мая 1991 года № 1244-1 «О социальной защите граждан, подвергшихся воздействию радиации вследствие катастрофы на Чернобыльской АЭС» имеет право на внеочередное обеспечение земельным участком для индивидуального жилищного строительства, который, по его мнению, должен быть предоставлен ему бесплатно.

В связи с этим гражданин Р.К. Галимов обратился в Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани с заявлением о предоставлении ему, как участнику ликвидации последствий катастрофы на Чернобыльской АЭС, земельного участка для индивидуального жилищного строительства бесплатно и во внеочередном порядке. Однако в предоставлении земельного участка заявителю было отказано со ссылкой на отсутствие в Республике Татарстан нормативной правовой базы, регулирующей порядок предоставления земельных участков участникам ликвидации последствий катастрофы на Чернобыльской АЭС.

Как считает гражданин Р.К. Галимов, федеральный законодатель, определив в подпункте 7 статьи 39.5 Земельного кодекса Российской Федерации, что земельный участок, находящийся в государственной или муниципальной собственности, предоставля-

ется в собственность бесплатно на основании решения уполномоченного органа иным не указанным в подпункте 6 данной статьи отдельным категориям граждан в случаях, предусмотренных законами субъектов Российской Федерации, передал законодателю субъекта Российской Федерации полномочие на осуществление соответствующего правового регулирования, в том числе на установление порядка предоставления земельных участков категориям граждан, имеющим на них право на основании Закона Российской Федерации «О социальной защите граждан, подвергшихся воздействию радиации вследствие катастрофы на Чернобыльской АЭС».

Между тем, как указывает заявитель, законодатель Республики Татарстан, установив в статье 32 Земельного кодекса Республики Татарстан случаи предоставления земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, в собственность граждан и юридических лиц бесплатно, не предусмотрел возможности предоставления земельных участков категориям граждан, имеющим на них право на основании Закона Российской Федерации «О социальной защите граждан, подвергшихся воздействию радиации вследствие катастрофы на Чернобыльской АЭС», чем нарушил его конституционные права.

Кроме того, по мнению заявителя, внеочередное обеспечение земельными участками не может осуществляться на аукционе, как это предлагает в своих ответах Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани.

На основании изложенного гражданин Р.К. Галимов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать статью 32 Земельного кодекса Республики Татарстан не соответствующей статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 32, 54 (часть первая), 55 и 58 Конституции Республики Татарстан.

2. Определяя основные принципы земельного законодательства, Земельный кодекс Российской Федерации выделяет в том числе принцип платности использования земли, согласно которому любое использование земли осуществляется за плату, за исключением случаев, установленных федеральными законами и законами субъектов Российской Федерации (подпункт 7 пункта 1 статьи 1).

С 1 марта 2015 года случаи бесплатного предоставления земельного участка, находящегося в государственной или муниципальной собственности, гражданину или юридическому лицу в собственность определены статьей 39.5 Земельного кодекса Российской Федерации. При этом непосредственно сам Земельный кодекс Российской Федерации, равно как и иные федеральные законы, не предусматривает в качестве такого случая предоставление на бесплатной основе земельного участка для индивидуального жилищного строительства участникам ликвидации последствий катастрофы на Чернобыльской АЭС. Из буквального содержания положений статьи 15 в их взаимосвязи с пунктом 8 части 1 статьи 14 Закона Российской Федерации от 15 мая 1991 года № 1244-1 «О социальной защите граждан, подвергшихся воздействию радиации вследствие катастрофы на Чернобыльской АЭС» следует,

что федеральное законодательство гарантирует рассматриваемой категории граждан при наличии нуждаемости в улучшении жилищных условий лишь преимущественное (внеочередное) право на обеспечение земельными участками.

При таких обстоятельствах само по себе отсутствие в статье 32 Земельного кодекса Республики Татарстан указания на участников ликвидации последствий катастрофы на Чернобыльской АЭС в числе лиц, которым предоставлена возможность бесплатного получения земельного участка, находящегося в государственной или муниципальной собственности, не может считаться нарушением конституционных прав и свобод граждан, в том числе и заявителя, поскольку предоставление такой возможности выступает в качестве дополнительной меры социальной поддержки, установление которой является правом, а не обязанностью Республики Татарстан, и зависит от имеющихся на данном этапе социально-экономического развития финансовых и иных материальных возможностей.

Такой вывод согласуется и с позицией Конституционного Суда Российской Федерации, который неоднократно указывал, что Конституция Российской Федерации не гарантирует бесплатное предоставление земельных участков (определения от 15 января 2009 года № 105-О-О, от 24 февраля 2011 года № 163-О-О и др.). В силу статей 10 и 72 (пункты «в», «ж» части 1) Конституции Российской Федерации, а также пункта 2 статьи 28 Земельного кодекса Российской Федерации, действовавшего до 1 марта 2015 года, определение оснований, круга лиц и условий для бесплатного предоставления земли относится к компетенции федерального законодателя и законодателя субъекта Российской Федерации, которые располагают достаточно широкой свободой усмотрения при разрешении указанного вопроса (определения от 22 марта 2012 года № 523-О-О, от 25 февраля 2013 года № 193-О, от 21 ноября 2013 года № 1831-О, от 24 декабря 2013 года № 2134-О, от 24 марта 2015 года № 582-О).

Таким образом, оспариваемая норма не содержит какой-либо неопределенности в указанном заявителем аспекте, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданина Р.К. Галимова не является допустимой. Расширение же перечня категорий граждан, которым предоставлено вышеназванное право, на чем фактически настаивает заявитель, предполагает внесение изменений в действующее земельное законодательство, что входит в компетенцию законодателя и не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Относительно доводов заявителя о незаконности проведения торгов при предоставлении гражданам земельных участков во внеочередном порядке следует отметить, что данные вопросы регламентируются главой V.1 Земельного кодекса Российской Федерации, в частности статьей 39.6, согласно которой гражда-

нам, имеющим право на внеочередное приобретение земельных участков, земельные участки предоставляются однократно без проведения торгов только в аренду.

При этом проверка конституционности указанных норм федерального законодательства, равно как и оценка обоснованности решений, принятых правоприменительными органами при рассмотрении обращений гражданина Р.К. Галимова, в том числе законности отказа в предоставлении ему земельного участка, также не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Р.К. Галимова на нарушение его конституционных прав и свобод статьей 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленных заявителем вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину Р.К. Галимову, в Государственный Совет Республики Татарстан и в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 30-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.К. Галимов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2017 ел
10 июль
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Р.К. Галимов шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Р.К. Галимов Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган норма дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә бирү мәсьәләләрен җайга сала, шул исәптән шундый җир кишәрлекләрен түләүсез бирү очракларын билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — 1988 елда Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучы. Гражданин Р.К. Галимов билгеләгәнчә, ул торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 14 статьясындагы беренче өлешенең 8 пункты нигезендә индивидуаль торак төзелеше өчен, аның фикеренчә, аңа түләүсез бирелергә тиешле җир кишәрлеге белән чираттан тыш тәэмин ителергә хокуклы.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин Р.К. Галимов Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитетына аңа, Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучы буларак, индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлеген түләүсез һәм чираттан тыш тәртиптә бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән. Ләкин Татарстан Республикасында Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучыларга җир кишәрлекләрен бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый базаның булмавына сылтама ясалып, мөрәҗәгать итүчегә җир кишәрлеген бирүдән баш тартылган.

Гражданин Р.К. Галимов санавынча, федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясындагы 7 пунктчасында дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге милек итеп Россия Федерациясе субъектлары за-

коннарында каралган очракларда әлеге статьяның 6 пунктчасында күрсәтелмәгән башка гражданнарның аерым категорияләренә вәкаләтле орган карары нигезендә түләүсез бирелә дип билгеләп, Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысына тиешле хокукый җайга салуны гамәлгә ашыру, шул исәптән «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә аларга хокуклары булган гражданнар категорияләренә җир кишәрлекләрен бирү тәртибен урнаштыру вәкаләтен тапшырган.

Шул ук вакытта, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы закон чыгаручысы Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясында дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә түләүсез бирү очракларын билгеләп, «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә аларга хокуклары булган гражданнар категорияләренә җир кишәрлекләрен бирү мөмкинлеген күздә тотмаган, шуның белән аның конституциячел хокукларын бозган.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, җир кишәрлекләре белән чираттан тыш тәэмин итү, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты җавапларында тәкъдим ителгәнчә, аукционда гамәлгә ашырыла алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Р.К. Галимов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 32, 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Җир законнарының төп принципларын билгеләп, Россия Федерациясе Җир кодексы шул исәптән җирдән файдалануның түләүлелеге принцибын бүлеп чыгара, аның буенча, федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары билгеләгән очраклардан тыш, җирдән теләсә нинди файдалану түләүле башкарыла (1 статьяның 1 пунктындагы 7 пунктчасы).

2015 елның 1 мартыннан дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнар һәм юридик затлар милкенә түләүсез бирү очраклары Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясы белән билгеләнгән. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Җир кодексы үзе, башка федераль законнар кебек үк, андый очрак буларак Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучыларга индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлеген түләүсез нигездә бирүне күздә тотмый. «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясы нигезләмәләренең 14 статьясындагы

1 өлешенең 8 пункты белән үзара бәйләнештә сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, федераль законнар гражданнарның карала торган категориясенә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык булганда җир кишәрлекләре белән тәэмин ителүгә өстенлекле (чираттан тыш) хокукны гына гарантияли.

Шундый шартларда Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясында Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучыларны дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез алу мөмкинлеге бирелгән затлар исәбендә күрсәтүнең булмавы үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дә конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозу дип санала алмый, чөнки андый мөмкинлекне бирү өстәмә социаль ярдәм чарасы булып тора, аны билгеләү Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы булып тора һәм әлеге социаль-икътисади үсеш этабында булган финанс һәм башка материаль мөмкинлекләргә бәйле.

Мондый нәтиҗә Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә дә туры килә, ул Россия Федерациясе Конституциясенең җир кишәрлекләрен түләүсез бирүне гарантияләмәве турында берничә мәртәбә искәртте (2009 елның 15 гыйнварындагы 105-О-О номерлы, 2011 елның 24 февралендәге 163-О-О номерлы һ.б. билгеләмәләр). Россия Федерациясе Конституциясенең 10 һәм 72 (1 өлешнең «в», «ж» пунктлары) статьялары, шулай ук Россия Федерациясе Җир кодексының 2015 елның 1 мартына кадәр гамәлдә булган 28 статьясындагы 2 пункты нигезендә җирне түләүсез бирү өчен нигезләрне, затлар даирәсен һәм шартларны билгеләү федераль закон чыгаручы һәм Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысы компетенциясенә керә, күрсәтелгән мәсьәләне хәл иткәндә алар җитәрлек дәрәҗәдә киң карамак ирегенә ия (2012 елның 22 мартындагы 523-О-О номерлы, 2013 елның 25 февралендәге 193-О номерлы, 2013 елның 21 ноябрендәге 1831-О номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 2134-О номерлы, 2015 елның 24 мартындагы 582-О номерлы билгеләмәләр).

Шулай итеп, дәгъвалана торган нормада мөрәҗәгать итүче күрсәткән аспектта нинди дә булса билгесезлек юк, шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданин Р.К. Галимов шикаяте карала алмый. Югарыда аталган хокук бирелгән гражданнар категорияләре исемлеген киңәйтү, мөрәҗәгать итүче шуңа басым ясый да, гамәлдәге җир законнарына үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә закон чыгаручы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Мөрәҗәгать итүченең гражданнарга җир кишәрлекләрен чираттан тыш тәртиптә биргәндә сатулашу үткәрүнең законсыз булуы турындагы дәлилләренә килгәндә, шуны билгеләп үтәргә кирәк: әлеге мәсьәләләр Россия Федерациясе Җир кодексының

V.1 бүлеге, аерым алганда, 39.6 статьясы белән җайга салына, аның нигезендә җир кишәрлекләрен чираттан тыш алу хокуклары булган гражданнарга җир кишәрлекләре сатулашу үткәрелмичә арендага бер тапкыр гына бирелә.

Шул ук вакытта федераль законнарның күрсәтелгән нормаларының конституциячеллеген тикшерү, гражданин Р.К. Галимов мөрәҗәгатьләрен караганда хокук куллану органнары кабул иткән карарларның нигезле, шул исәптән аңа җир кишәрлеген бирүдән баш тартуның законлы булу-булмавын бәяләү кебек, Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә шулай ук керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.К. Галимов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Р.К. Галимовка, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 30-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.С. Насыровой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 1 и 2 постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 27 декабря 2016 года № 5320 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2017 год»**

12 июля
2017 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки А.С. Насыровой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка А.С. Насырова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 1 и 2 постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 27 декабря 2016 года № 5320 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2017 год». Пунктами 1 и 2 оспариваемого постановления утверждаются, вводятся в действие и считаются действующими с 1 января 2017 года до 30 июня 2017 года и с 1 июля 2017 года до 31 декабря 2017 года соответственно размеры платы за содержание жилых помещений для нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного или муниципального жилищного фонда, а также собственников помещений в многоквартирных домах, не принявших решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание жилых помещений, по видам услуг.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка А.С. Насырова является собственником жилого помещения в многоквартирном доме, размер платы за содержание жилых помещений в котором на общем собрании собственников не был установлен и рассчитывается в соответствии с рассматриваемым нормативным правовым актом.

Заявительница указывает, что согласно Жилищному кодексу Российской Федерации размер платы за содержание жилого помещения в многоквартирном доме устанавливается на срок не менее чем один год. Однако, по ее мнению, оспариваемые нормы устанавливают размер данной платы два раза в год, чем противоречат Конституции Республики Татарстан и нарушают ее конституционные права.

На основании изложенного гражданка А.С. Насырова просит

Конституционный суд Республики Татарстан признать пункты 1 и 2 постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 27 декабря 2016 года № 5320 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2017 год» не соответствующими статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49 и 51 Конституции Республики Татарстан.

2. Из положений части 3 статьи 156 и части 4 статьи 158 Жилищного кодекса Российской Федерации следует, что, если собственники жилых помещений не приняли решение о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на их общем собрании не приняли решение об установлении размера платы за содержание жилого помещения, такой размер устанавливается органом местного самоуправления. Тем самым обжалуемое заявительницей постановление принято Исполнительным комитетом муниципального образования города Казани в рамках реализации приведенных норм федерального законодательства и, исходя из своей правовой природы, распространяется на собственников помещений в многоквартирных домах, которые не воспользовались своим правом на самостоятельное принятие решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) об установлении размера платы за содержание жилых помещений по видам услуг.

Анализ оспариваемого правового регулирования показывает, что установленные постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 27 декабря 2016 года № 5320 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2017 год» размеры платы за содержание жилых помещений для собственников помещений в многоквартирных домах на первое и второе полугодия 2017 года отличаются. При этом размер платы за содержание жилых помещений для собственников помещений в многоквартирных домах на первое полугодие 2017 года соответствует размеру такой платы, предусмотренному постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год» на второе полугодие 2016 года.

Такой подход согласуется с правоприменительной практикой, сложившейся на федеральном уровне, поскольку по решению Правительства Российской Федерации изменение тарифов происходит только один раз в год с первого июля. Так, в соответствии с распоряжением Правительства Российской Федерации от 19 ноября 2016 года № 2464-р индексы изменения размера вносимой гражданами платы за коммунальные услуги на 2017 год установлены дифференцированно на периоды с 1 января по 30 июня и с 1 июля по 31 декабря.

Таким образом, срок, в течение которого установленный Исполнительным комитетом муниципального образования города Казани размер платы за содержание жилых помещений остается

неизменным, составляет один год, что отвечает требованиям взаимосвязанных положений части 7 статьи 156 Жилищного кодекса Российской Федерации и пункта 31 Правил содержания общего имущества в многоквартирном доме, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 13 августа 2006 года № 491, в силу которых размер платы за содержание жилого помещения в многоквартирном доме определяется с учетом предложений управляющей организации и устанавливается на срок не менее чем один год.

При таких обстоятельствах обжалуемые заявительницей нормы не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки А.С. Насыровой не является допустимой.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.С. Насыровой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 1 и 2 постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 27 декабря 2016 года № 5320 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2017 год», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке А.С. Насыровой и в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 31-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарының 1 һәм 2 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Ә.С. Насыйрова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2017 ел
12 июль
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Ә.С. Насыйрова шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Ә.С. Насыйрова «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарының 1 һәм 2 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъвалана торган карарның 1 һәм 2 пунктлары белән социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә тиешенчә 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 30 июненә кадәр һәм 2017 елның 1 июленнән 2017 елның 31 декабренә кадәр торак урыннарны карап тотуга түләү күләме хезмәт төрләре буенча раслана, гамәлгә кертелә һәм гамәлдә дип санала.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Ә.С. Насыйрова — күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе, әлеге йортта милекчеләрнең гомуми җыелышында торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме билгеләнмәгән һәм ул карала торган норматив хокукый акт нигезендә исәпләнә.

Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту өчен түләү күләме кимендә бер елга билгеләнә дип күрсәтә. Ләкин, аның фикеренчә, дәгъвалана торган нормалар әлеге түләү күләмен елга ике тапкыр билгелиләр, шуның белән Татарстан

Республикасы Конституциясенә каршы киләләр һәм аның конституциячел хокукларын бозалар.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Ә.С. Насыйрова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарының 1 һәм 2 пунктларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 3 өлеше һәм 158 статьясындагы 4 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре мәгънәсеннән чыгып, әгәр торак урыннар милекчеләре күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән һәм (яки) үзләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән булсалар, мондый күләм җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә. Шуның белән мөрәҗәгать итүче дәгъвалый торган карар Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан федераль законнарның китерелгән нормаларын гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителгән һәм, үзенең хокукый табигатеннән чыгып, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) хезмәт төрләре буенча торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында мөстәкыйль карар кабул итү хокукыннан файдаланмаган күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә кагыла.

Дәгъвалана торган хокукый җайга салуны анализлау шуны күрсәтә: «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карары белән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә 2017 елның беренче һәм икенче яртыеллыкларына торак урыннарны карап тоту өчен билгеләнгән түләү күләме аерыла. Шул ук вакытта күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә 2017 елның беренче яртыеллыгына торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы карары белән 2016 елның икенче яртыеллыгына каралган шундый түләү күләменә туры килә.

Мондый алым федераль дәрәҗәдә урнашкан хокук куллану практикасына туры килеп тора, чөнки Россия Федерациясе Хөкүмәте карары буенча тарифлар елга бер тапкыр гына беренче июльдән үзгәрә. Шулай, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 ноябрендәге 2464-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә 2017 елга коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар кертә торган түләү

күләменең үзгәрү индекслары 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәрге һәм 1 июльдән 31 декабрьгә кадәрге чорлар өчен төрлечә билгеләнгән.

Шулай итеп, торак урыннарны карап тоту өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән түләү күләме үзгәрми торган вакыт бер ел тәшкил итә, бу Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 7 өлешенең һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрендәге 31 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре таләпләренә җавап бирә, алар нигезендә күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту өчен түләү күләме идарәче оешма тәкъдимнәрен исәпкә алып, кимендә бер елга билгеләнә.

Мондый шартларда мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган нормаларда аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданка Ә.С. Насыйрова шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарының 1 һәм 2 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Ә.С. Насыйрова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Ә.С. Насыйровага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 31-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.П. Луговниной на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»**

12 июля
2017 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.П. Луговниной,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.П. Луговнина с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан № 63-ЗРТ).

Оспариваемым пунктом установлено, что меры адресной социальной поддержки пенсионеров, работников государственных и муниципальных учреждений, малоимущих граждан, граждан, имеющих право на безвозмездное обеспечение лекарственными средствами, осуществляются на основании решений Кабинета Министров Республики Татарстан и органов местного самоуправления в пределах средств, предусмотренных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и бюджетами муниципальных образований.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница является пенсионером и ей назначена ежемесячная денежная выплата на проезд в соответствии с Положением о порядке предоставления денежных выплат, пособий, субсидий и стипендий отдельным категориям населения в Республике Татарстан, утвержденным постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 17 декабря 2004 года № 542. В связи с прекращением трудовой деятельности она обратилась с заявлением о пересмотре размера ежемесячной денежной выплаты на проезд в Государственное учреждение — Управление Пенсионного фонда Российской Федерации в Приволжском районе города Казани Республики Татарстан, отделение Республиканского центра материальной помощи (компенсационных выплат) по Приволжскому району города Казани и в Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан, однако в перерасчете ей было отказано.

Гражданка Г.П. Луговнина усматривает нарушение своих конституционных прав в том, что оспариваемая норма ставит перечисленные в ней категории граждан, в том числе пенсионеров, в неравное положение с иными категориями граждан, меры адресной

социальной поддержки которым непосредственно установлены в самом Законе Республики Татарстан № 63-ЗРТ. По мнению заявительницы, такое различие в предоставлении мер социальной поддержки одним категориям граждан законом Республики Татарстан, а другим — на основании решений Кабинета Министров Республики Татарстан и органов местного самоуправления не соответствует конституционному принципу равенства и нарушает ее конституционные права.

На основании изложенного гражданка Г.П. Луговнина просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 2 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» не соответствующим статьям 27 (часть первая), 28 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая), 30, 32, 38 (часть первая), 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

